Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение – Аланская средняя общеобразовательная школа Тюлячинского муниципального района

Республики Татарстан

| Рассмотрено | Согласовано | Утверждаю |
| --- | --- | --- |
| на заседании ШМО классных руководителей | Заместитель директора по ВР | Директор МБОУ - Аланская средняя общеобразовательная школа Тюлячинскогомуни-ципального района РТ |
| ____________ /Фаттахова А.Г../ | МБОУ - Аланская средняя общеобразовательная школа | ________ /И.Б.Гайбадуллин/ |
| Протокол № 1 | Тюлячинскогомуниципаль-ного района РТ | Приказ № 166 |
| от «29» августа 2023г. | ________ /Гатауллина Д.Г./ | от «29» августа 2023г. |
| | от «29» августа 2023г. | |

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**

курса внеурочной деятельности «Мавыктыргыч грамматика» для 2 класса

составитель: Хасанова ГульсияАхматовна

классный руководитель 2 класса

Принято педагогическим советом

протокол № 1 от «29» августа 2023г.

2023г.

## Башлангыч сыйныфлар өчен «Мавыктыргыч грамматика” дәрестән тыш эшчәнлек программасы

## Аңлатма язуы

«Мавыктыргыч грамматика» курсына эш программасы башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә туры китереп, башлангыч сыйныф укучыларының танып белү сәләтләрен үстерү өчен төзелгән.

Программаны гамәлгә ашырганда “Кызыклы грамматика”. Вагизов С.Г. К.: “Мәгариф” нәшрияты, 2002; “Уйнап укый балалар”. Зиннурова Ф.М. К.: “Мәгариф” нәшрияты, 2007 методик әсбаплары кулланыла

Бу курс укучыларга сүз дөньясының, татар  грамотасы дөньясының никадәр мавыктыргыч, төрле, бетмәс-төкәнмәс булуын күрсәтергә мөмкинлек бирә. Бу уку эшчәнлеге нигезләре буларак чын танып белү кызыксынуларын формалаштыру өчен зур әһәмияткә ия.

Программа башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә туры китереп төзелгән.

**Программаның максаты**: башлангыч мәктәп укучыларында татар теленнән белемнәрне, укучыларның лингвистик күзаллауларын үстерү дәресләре системасы аша киңәйтү, тирәнәйтү һәм ныгыту.

**Бурычлары:**

- укучыларның лингвистик компетенцияләрен үстерү;

- татар  теленә мәхәббәт һәм хөрмәт формалаштыру;

- башлангыч мәктәп укучыларының танып белү сәләтләрен үстерү;

- башлангыч сыйныф укучыларының иҗади сәләтләрен үстерү;

- укучыларның күзаллауларын киңәйтү.

Программа башлангыч мәктәптә өч ел дәвамында (2 нче сыйныфтан 4 нче сыйныфка кадәр) гамәлгә ашырыла. Дәрестән тыш эшчәнлек һәр укучыга аның сәләтләрен исәпкә алып, индивидуаль якын килүне уңышлы кулланырга, укучыларның танып белү һәм тормыш мәнфәгатьләрен тулырак канәгатьләндерергә мөмкинлек бирә.

**Актуальлеге:**
Курс нигезендә торган төп принцип-мавыктыргычлык. Һәр дәрес уен элементлары белән биремнәргә, уеннарга, табышмакларга, шифрлауларга, кроссвордларга, ребусларга, грамматик әкиятләргә һәм шигырьләргә нигезләнә, бу татар телен өйрәнүгә, материалны җиңел үзләштерүгә һәм истә калдыруга җанлы кызыксынуны сакларга ярдәм итә. Бүгенге ваәзгыять туган телебезгә сак караш, тел нигезләренә хөрмәт- мәхәббәт тәрбияләүне дә бурыч итеп куя. Авторлык программасы шуларны истә тоткан хәлдә эшләнде. Программа үз эченә дәрес материаллары белән бәйләнешле булган өстәмә материалларны ала. Кызыклы, мавыктыргыч уеннар, фонетик күнегүләр авазларны дөрес әйтүгә этәргеч булып тора. Башка программалардан аермалы буларак, күнегүләр өчен материал туган авылыбыздан чыккан язучы, шагыйрә Равилә –Шәйдуллина Морат китапларыннан алынды. Программа үз эченә туган төбәккә, аның күренекле кешеләренә мәхәббәт тәрбияләү чыганагы да булып тора. Тел белән әдәбият бәйләнешле алып барылу да программаның актуальлеген үстерә.

## Гомуми характеристика

“Мавыктыргыч грамматика” курсы-укучыларның татар теле дәресләрендә алган белемнәрен ныгытуга, киңәйтүгә һәм тирәнәйтүгә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләүгә һәм аны өйрәнүгә омтылуга, шулай ук укучыларның танып белү сәләтләрен, аларның психик сыйфатларын: хәтер, игътибар, фикерләү, күзаллау, сөйләм үстерү өчен шартлар тудыру юнәлдерелгән.

Һәр дәреснең түбәндәге структурасы бар:
1) дәрес темасы өстендә эш;
2) дәрес темасына буйсынучы төп эшчәнлек төреннән икенчесенә күчү. Шигырьләр уку һәм алардан мәгълүмат алу;
3) тема өстендә эшне дәвам итү.

## Көтелгән нәтиҗәләр

Шәхескә караган нәтиҗәләр:
-Сөйләмнең матурлыгын һәм сәнгатьлелен тою, үз сөйләмеңне камилләштерергә омтылу
-Туган илгә, туган телгә, мәдәнияткә хөрмәт һәм мәхәббәт
- телне өйрәнүгә кызыксыну;
-әйткән һәм язган сүзгә җаваплылыкны аңлау.

Регулятив УДД:
дәреснең темасын һәм максатын үзлектән формалаштыру;
уку проблемасын чишү планын укытучы белән бергәләп төзү;
максат белән чагыштырып, план нигезендә эшләү.
Танып белү УУД:
мәгълуматны бер формадан икенчесенә үзгәртү;
сүзлекләр һәм белешмәләр куллану;
фикер йөртә алу.
Коммуникатив УУД:
сөйләм чараларын төрле коммуникатив бурычларны хәл иткәндә дөрес куллану;
үз фикереңне дөрес һәм нигезле аңлата алу;
башкаларны тыңлый һәм ишетә алу ; уртак эшчәнлектә гомуми чишелешне табу.
Предмет нәтиҗәләре
-сүзләрне иҗекләргә дөрес бүлү, басымын билгеләү, тамырдаш сүзләрне табу;
-капма- каршы мәгънәдәге сүзләрне табу, сүзлек белән эшли алу;
- фразеологизмнар сайлый алу, сөйләмдә мәкальләрдән файдалану;
- сөйләмдә алмашлыклар, саннар һәм рәвешләр куллана алу.

**Курсның төп эчтәлеге**
1 нче Тема. Фонетика.
Теория: татар теленең авазлары турында белемнәрне киңәйтү, «баш мие һөҗүме».
Практика: «хаталарны төзәт» уены, орфографик хаталар ясалган әсәрләр белән эшләү, Орфографик үткенлекне формалаштыру өчен иҗади биремнәр.
2 нче Тема. Сүз төзелеше.
Теория: сүзнең өлешләре, аларның сүз төзелешендә мәгънәсе турында белемнәрне киңәйтү, «баш мие һөҗүме».

Практика: сүзләрне үзгәртү уеннары, схемалар белән эшләү, шарадлар, татар теленә танып белү кызыксынуын үстерү өчен Логик-эзләү биремнәре.
3 нче Тема. Сүзлек.
Теория: татар теленең байлыгы турында сөйләшү «яхшы сүзләр», телнең неологизмнары һәм архаизмнары, фразеологизмнары белән танышу.
Практика: укучыларның сүзлек запасын киңәйтү уеннары, сүзлекләр һәм энциклопедияләр белән эшләү, сөйләмдә фразеологик әйләнешләрне актив куллану, татар теленә танып белү кызыксынуын үстерүгә логик-эзләү биремнәре.

4 нче Тема. Морфологиясе.
Теория: сөйләм өлешләре, аларның морфологик билгеләре турында белемнәрне киңәйтү.
Практика: сөйләм өлешләрен белү, фразаларны һәм текстларны чишү, татар теленә танып белү кызыксынуын үстерү өчен Логик-эзләү биремнәре.
5 нче Тема. Мәкальләр һәм әйтемнәр.
Практика: сөйләмдә мәкальләрне һәм әйтемнәрне актив куллану, бирелгән ситуациягә мәкальләрне сайлап алу.
6 нчы Тема. Уеннар.
Практика: танып белү сәләтләрен үстерүгә, табышмакларны чишүгә, кроссвордларны, криптограммаларны чишүгә, белемгә һәм туган телгә кызыксынуны үстерүгә, татар теленнән белемнәрне тикшерүгә юнәлдерелгән логик-эзләү биремнәре.

**Тематик планлаштыру**

| №п/п | Тема | Сәгать саны | Белем һәм күнекмәләр, көтелгән нәтиҗәләр | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Танышу. Дидактик уеннар. Р.Шәйдуллинаның “Елак болыт” шигыре. | 1 | Аваз һәм хәрефләрне барлау. Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңларга тырышу, аралашканда әдәплелек кагыйдәләрен куллана белү,әңгәмәдә катнашу, бер-береңә дустанә мөнәсәбәттә булу. | |
| 2 | Ребуслар чишәргә өйрәнәбез. Сүз төзелеше.“Татарстан шәһәрләре”(Авыллары). “Батыр малай” шигыре. | 1 | Татарстан шәһәрләре белән танышу, игътибарлы, күзәтүчән булу,шәһәр исемнәрен дөрес яза белү, рус телендәге тәрҗемәсе белән чагыштыру, охшаш, аермалы | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | якларын таба белү, ребус чишәргә өйрәнү. | |
| 3 | Дидактик уеннар. Морфология. “Тематик лото”. “Батыр малай” шигыре. | 1 | Фикерли, уйлый белү, игътибарлы, күзәтүчән булу, татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру, рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү, сүзләрне бер төркемгә туплый алу, ул төркемнәрне атау. | |
| 4 | Тапкырларга – табышмак. Сүзлекләр. “Алмагач дәресе” шигыре. | 1 | Фикерли, уйлый белү, игътибарлы, күзәтүчән булу, табышмакларны чишәргә өйрәнү һәм үзең табышмак уйлый алу, парларда һәм күмәк белән эшли белү. | |
| 5 | Кроссвордлар төзү һәм чишү. “Йолдыз яңгыры” шигыре. | 1 | Фикерли, уйлый белү, игътибарлы, күзәтүчән булу, кроссвордларны чишәргә өйрәнү, атамаларны дөрес язарга өйрәнү | |
| 6-7 | Дидактик уеннар “Телеграмма” “Бәхетле очрак” | 2 | Аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәнү, коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу | |
| 8-9 | Шарадалар | 2 | Шарадаларны чишә белү, ж, ң, һ хәрефләре кергән | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | “Күп укыган, күп белер”. “Җиллəрдəн җиңел күлмəк” шигыре. | | сүзлəрнең дөрес язылышын үзлəштерү | |
| 10 | Сүз уеннары “Иҗек аукционы” | 1 | Сүзлəрне иҗеклəргə бүлү һəм юлдан-юлга күчерə белү, грамматик формаларны бер-берсеннəн ишетү аша аерырга өйрəнү, фикерли белү күнекмəлəрен үстерү. | |
| 11 | Тизəйткеч-телебезне төзəткеч. | 1 | Татар теленə хас үзенчəлекле авазларны дөрес əйтə белү, аларны ишетеп таный белү, парларда һəм күмəк эшли белү, ишетү хəтеренең күлəмен үстерү. | |
| 12 | Дидактик уеннар “Буяу сатышлы”. “Урланган ай” шигыре. | 1 | Сайланган эчтəлек аша əңгəмəдешеңə кире кага, раслый белү, буяу атамаларын истə калдыру, шəхесара һəм мəдəниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру. | |
| 13 | Башваткычлар чишү | 1 | Фикерли, уйлый белү, игътибарлы, күзəтүчəн булу, татар телендəге сүзлəрнең сингармонизм законына бусынуын яки буйсынмавын аңлау. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 14 | Мәкальләр дөньясында | 1 | Татар халык мәкальләре белән танышу, мәгънәләрен аңлата белү, әңгәмәдә катнашу нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша, мәгънәсен аңлау. | |
| 15 | Анаграммалар | 1 | Анаграммаларны чишә белү, ә,ү,ө хәрефләре кергән сүзләрнең дөрес язылышын үзләштерү | |
| 16 | Тел көрмәкләндергечләр | 1 | Тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү, татар теленә хас үзенчәлекле авазларны дөрес әйтә белү, аларны ишетеп таный белү, парларда һәм күмәк эшли белү. | |
| 17 | Тапкырлар клубы. “Кабык арба” шигыре. | 1 | Әхлакый кагыйдәләрдә ориентирлашу, аларны өйрәнүнең мәҗбүрилеген аңлау,татар телен яхшы өйрәнү теләге формалаштыру, татар милләтенең мәдәнияте белән кызыксыну | |
| 18 | “Тәрҗемәче” уен-ярыш | 1 | Өйрәнелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү, парларда һәм күмәк эшли белү, аңлаган мәгълүмат | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | турында фикер йөртергә өйрәнү | |
| 19 | “Татарча да яхшы бел”. | 1 | Рәсем буенча җөмләләр төзү күнекмәләрен арттыру, өйрәнгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү, чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен камилләштерү. | |
| 20 | “Ромашка” уены. Саннар | 1 | Саннарны искә төшерү, саннар кергән шигырьләрне уку, тәрҗемә итү, диалог төзү. | |
| 21 | Комплиментлар әйтәбез | 1 | Бер-береңә комплиментлар әйтә белү, парларда һәм күмәк эшли белү | |
| 22 | Татар халык ашлары. Дидактик уеннар “Тематик лото”. | 1 | Фикерли, уйлый белү, игътибарлы, күзәтүчән булу, , татар милләтенең мәдәнияте белән кызыксыну, татар халык ашлары турында мәгълүмат туплау | |
| 23 | “Кем булып эшли?” -чы/-че сүз ясагыч кушымчалары | 1 | Әти-әниләрнең кем булып, кайда эшләвен, профессия исемнәрен әйтә белү. | |
| 24 | Антонимнар. Уеннар. “Әйе-юк димәскә, ак-карага тимәскә” | 1 | Капма-каршы мәгънәле сүзләрне аерырга өйрәтү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 25 | Синонимнар. Дидактик уеннар | 1 | Охшаш мәгънәле сүзләрне сөйләмдә куллану, чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен камилләштерү. | |
| 26 | Омонимнар. Дидактик уеннар | 1 | Язылышы һәм әйтелеше бертөрле, мәгънәләре үзгә булган сүзләр белән танышу, рус телендәге омоним сүзләр белән чагыштыру, аларны сөйләмдәдөрес куллану. | |
| 27 | Әдәпле сүзләр дөньясында. “Урланган ай” шигыре. | 1 | Әдәплелек кагыйдәләрдә ориентирлашу, аларны үтүнең мәҗбүрилеген аңлау,татар телен яхшы өйрәнү теләге формалаштыру | |
| 28 | Халык әйтсә, хак әйтә. Халык җырлары. “Әпипә” | 1 | Татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру, халык җырлары белән танышу, ошаганын ятлау. | |
| 29 | Санамышлар. “Чебиләр” шигыре. | 1 | Санамышлар белән танышу, аларны куллану, татар телен яхшы өйрәнү теләге формалаштыру | |
| 30 | Сүз уеннары. Ребуслар. “Шаян песи” шигыре. | 1 | Фикерле, уйлый белү, игътибарлы, күзәтүчән булу, ребусларны чишәргә өйрәнү һәм үзең ребус уйлый алу, | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | парларда һәм күмәк белән эшли белү. | |
| 31-32 | Проект эше “Кызыклы грамматика” | 2 | Ел дәвамында өйрәнгәннәрне кабатлау, проект эшләү, аны яклау | |
| 33 | Тапкырлар һәм зирәкләр клубы | 1 | Татар телен яхшы өйрәнү теләге формалаштыру, алган белем һәм күнекмәләрне куллана белү | |
| 34 | Йомгаклау “Татарча да яхшы бел” | 1 | | |